*Давлетова Люция Мадхатовна*

*Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение средняя общеобразовательная школа № 36*

*Орджоникидзевский район города Уфы, Республика Башкортостан*

**“Рәми Гарипов иҗатына сәяхәт”**

**Максаты:**

а) Шагыйрь иҗаты белән танышу, иҗаты турында әңгәмә;

б) Тугандаш халыкларының әдәбияты белән таныштыру;

в) Милләт-ара дуслык, татулык елында Башкорт халкының әдәбиятына, туган ягыбызга укучыларда хөрмәт хисе тәрбияләү.

**Җиһазлау:** Башкортостан картасы, рәсемнәр, шагыйрьнең җыентыклары.

I. Дәресне оештыру. Тел, әдәбият турында әңгәмә.

II. “Туган тел” шигырен тыңлау.

III. Теманы актуальләштерү. “Туган тел” турында әйтем, мәкальләр”.

IV. Р.Гариповның тормыш юлы.

V. а) Р.Гариповның дуслары һәм иптәшләре.

   б) “Җыр иленә сәяхәт. “Ялгыз аккош”, “Иминлек сөрәне” җырларын тыңлау.

VI. Иҗади эш. Р.Гарипов Башкортстанның киләчәген ничек күзаллый? Шигырь буенча эш “Башкортстан”, “Ялан чәчкәләре”.

VII. Йомагаклау. Шагыйрь турында уйланулар.


ISSN 2223-4063
www.konf-zal.com
konf-zal@mail.ru

**Дәреснең темасы “Рәми Гарипов иҗатына сәяхәт”**

**Рәми Гарипов елы конкурсына дәрес өлгесе “Ачык дәрес”.**

**Максат:**

а) Шагыйрьнең тормышы белән танышу, иҗатының әһәмияте турында әңгәмә;

б) Тугандаш халыкларының әдәбияты белән таныштыру;

в) Милләт-ара дуслык, татулык елында Башкорт халкының әдәбиятына хөрмәт тәрбияләү.

**Җиһазлау:** Башкортостан картасы, рәсемнәр.

**Дәресне оештыру.**

Укытучы. Курай моңы астында Г.Тукайның “Туган тел” шигыре укыла.

- Диалог. Укучылар, бу кем шигыре?
- “Туган тел” шигыре.
- Әйе, укучылар, бу шигырьне татар халкының сөекле улы Г.Тукай язган.
- Укытучы. Бу көй нинди? Шатлыклымы, сагышлымы?
- Балалар. Сагышлы, моңлы көй.
- Укытучы. Ә курай моңы башкорт далаларын, үрләрен, тауларын, ургылып аккан чишмәләрен хәтерләтә.
- Укытучы. Әйе, тугандаш халыкларыбыз арасында үзенең гүзәл иҗаты белән шигъри салават күперләре төсле ничәмә төр нур чәчеп калдырган шагыйрь, язучыларыбыз бар.

**Ялан чәчкәләре**

Мин яратам кала чәчкәләрен,
Яраткандай бала күзләрен
Бакчачылар, сабый сымак итеп,
Назлап үстерә бит үзләрен!

Иртән торып эшкә ашыкканда
Арып кайткан чакта кичләрен
Чәчкәләргә карап куанам мин
Чәчкә аткан төсле хисләрем.
Тик торсам гына, мин аларның
Тая торып хуш ис чәчкәнең
Әллә нигә кинәт сагнып китәм
Гади генә яман чәчкәсен.
Әллә инде мин үзем дә шулай
Тиң үскәнгә әрсез гөл белән.
Әче тирем тамган чәчәкләрне
Мин ныграк сөям шикелле.
Дөньядагы бөтен гөлләрдән дә
Шул чәчкәләр миңа сөйкемле

1 алып баручы.

Татар әдәбиятында Г.Тукай, Хәсән Туфан “Туган тел” турыныда гимн рәвешендә шигырь калдырганнар.

2 алып баручы.

Ә менә башкорт әдәбиятында Б.Бикбай, З.Биишева, Р.Гарипов та “Туган тел”гә багышлап шигырь язган. Р.Гариповның “Туган тел” шигырен.
(бер укучы укый “Туган тел”)

1 алып баручы.

Ә бит нинди мәгънәле сүзләр. Телебезне бал кортыдай саклап тотыйк.

**“Туган тел” турында әйтем мәкальләр.**

Укытучы. Ә хәзер “Туган тел” турында әйтемнәр, мәкальләр әйтеп китик.

“Иле барның теле бар,
Теле барның иле бар”.

“Туган телем иркә гөлем
Киңдер сиңа күңел түрем”.

“Туган телем гөл бакчасы”.

Ә хәзер Р.Гариповның гаилә архивын карап китик. Видеофильмнан аның тормыш юлын күрсәткән кадрлар күренә.

Укытучы. Һәркемнең иң кадерле кешесе була. Р.Гариповның да киңәшчесе, ярдәмчесе әнисе була. Рәми үзенең тәүге шигырьләрен әнисенә укыган була. Әйтегез әле, укучылар, Р.Гарипов кайда туган? Башлангыч белемне кайда алган (Салават районы, Аркауыл авылы)

Мультимедиядан Салауат районы, Янгантау санаториясен, шагыйрьнең туган авылын карау.

Укытучы. Мин сезгә Рами Гариповның дуслары турында кыскача белешмә язырга, өй эшен кушкан идем. Кем бу эшне башкарды?

Укучы. Рами Гариповның дуслары бик күп булган. Шуларның берсе Башкортостан егете, Татарстанда яшәп иҗат иткән – Роберт Миңнуллин.

Р.Миңнуллин белән Р.Гарипов студент елларында гел аралашып яшиләр. Р.Гарипов үзе дә Р.Миңнуллинга тәүге шигырьләрен укыта, алар икесе дә Уфа буйлап әкрен генә йөрергә яратканнар. Укучы. Р.Миңнуллин Р.Гариповка багышлап моңсу шигырь яза “Карыйм, карыйм Каратауга” (бер укучы бу шигырьне сәнгатьле укый)

2 укучы. Р.Миңнуллин зур талант иясе, Татарстаннның депутаты, Г.Тукай премиясе лауреаты, бу шигырь бик тә сагышлы, тирән моңсулы, кайгылы.

Шигырьда еш кына “телгәләнми, теленми, елый, түз, әрнисез, күңелсездер, Рәмисез” – дигән юллар бар. Дусының вафат булуын шагыйрь йөрәге авыр кичерә. Аны эзләп Каратуга, Салават районына бара, ләкин Рәмине таба алмый...

Дөрес, шигырьдә күңелне күтәрерлек юллар да бар.

“Күз явын ала чәчәкләр!

Их, китапка тезергә.

Рәми шигырьләре ул – кулым бармый өзәргә”.

Р.Гариповның шигырьләре күз явын алырлык, саф, матурлар, аларны өзәргә ярамый, чәчәкне өзәргә, ә шигырьне укырга кирәк.

**“Карыйм, карыйм Каратауга”**

Роберт Миңнуллин

Карадым да Каратауга,
Күрү белән таныдым:
Каратуны мин Рәминең
Җырларыннан таныдым.

Ничек түзсен, ди, бу йөрәк
Телгәләнми, теленми?!-
Монда аның шигърияте...
Рәми генә күренми.

Карыйм, карыйм Каратауга...
Җитә алмамдыр менеп.
Юкса бик күрәсем килә-
Рәми шундадыр кебек.

Юрүзәннең күңле тулган,
Сагыш агышларында.
Рәминең сагышлары ул,-
Йөзәм сагышларында.

Күз явын ала чәчәкләр!
Их, китапка тезәргә.
Рәми шигырьләре ул,-
Кулым бармый өзәргә.

Елый да елый Коргазак.
“Түз”,-дип аны юатам.
Рәми күз яшьләре белән
Иренемне чылатам.

Каратуда-ак каеннар...
Беләм, сез дә әрнисез.
Сезгә дә бик күңелсездер,
Ямансудыр Рәмисез.

Үземә дә бигрәк моңсу,
Сагыш көйдерә мине.-
Килгән идем бит бирегә,
Күрермен дип Рәмине.

Укытучы. Ә Р.Гарипов нинди темага багышлап шигырьләр язган соң?

**“Текст өстендә эш”.**

“Башкортостан” шигыре таратыла.
1 эш. Шигырьне сәнгатьле уку.

2 эш. Шигырьдәге эпитетларны табырга. Шагырь Башкортостанны “Җиркайгенәм”, “Җилкәйгенәм”, “Башкортостан-Бөркетстан”, ирекле бөркеткә тиңли.

3 эш. Шагырь Башкортостанның киләчәген ничек күз алдына китерә?
-Укучы. Шагыйрь туган төягебез, сөекле Башкортостаныбызны ирекле, канатлы, горур булуын күз алдына китерә һәм горурлана. Башка ил, башка төяк

аңа һич кирәкми, чөнки “Башкортостан-гөлләр иле”, анда аның йөрәк тибеше, җире, сулышы, гүзәл табигатьле оҗмах – ул Башкортостан.

**“Башкортстан”**

(чит илдән кайтышлый)

Башкортстан чиген үтү белән,
Туып-үскән җиргә җитә белән,
Нур тулгандай була күңелдә,
Җыр тулгандай була күңелдә.

Яшел бәрхет төсле җиркәйгенәм,
Кызлар кулы төсле җилкәйгенәм
Иркәли бит балган күземне,
Иркәли тир арыган йөземне.

Йөгереп чыгу белән каеннарым,
Онытылды барлык кайгыларым,
Күрү белән кәген Уралның,
Күзләремә яшьләр уралды...

Уйнаклашып чаба, әнә, тайлар...
Уйга килә яугир бабайлар-
Илен алар тиккә сөймәгән,
Илен, диеп тиккә көймәгән!

Башкортостан-безнең Бөркетстан,
Иркең курсып, күпме бөркет очкан!...
Башкортстан-йөрәк кагышым,
Җирсенмәсәм, төшсен каргышың!

Синсез күңелем ничек яшәсен,
Синсез зиһенем ничек яшьнәсен?
Башка җирдә ашым җыелмас,
Башка җиргә башым иелмәс...

Юк, кирәкми миңа аһ-ваһларың,
Ары торсын җәннәт-оҗмахларың,
Башкортостан-туган төягем,
Синдә ятсын, ятса, сөягем!...

1966ел

## Йомгаклау.

Сүзебезне татар халкының бөек шагыйре Г.Тукай сүзләре белән башлаган идек, бу юкка гына түгел. 1954 елда Р.Гарипов Казанга махсус бара һәм Г.Тукайга багышланган (Г.Тукай кабере янында уйлану) "Шагыйрь" исемле шигырен яза. Бу шигырьдә тугандаш республикада яшәгән, авыр тормыш шартларында иҗат иткән бөек шагыйребез Габдулла Тукайга тирән хөрмәт белән караганын, соклануын белдерә. Әйе, тугандаш халыклар һәрвакыт бер-берсенең иҗат ялкынында янып яшәгәннәр, элек тә, хәзер дә бер-берсенең әдәбиятын, телен, гөреф-гадәтләрен саклап калырга тырышканнар, тырышалар.

## "Шагыйрь"

Шигырь язды шагыйрь ачлы-туклы,
Туендырды илһам бакчасы.
Тик бурычын түләргә дә аның
Җитмәде шул тапкан акчасы!..

Ләкин шагыйрь башын ияме соң?
Язды, сызды, көн-төн эшләде.
Күз аллары аның томаланса,
Тик иренен генә тешләде.

Кансыз иде көйгән иреннәре,
Хәлсез иде кипкән куллары.
Хәйләсез бер сабый сыман аны
Юатты тик язган юллары...

Ул сизми дә калды-йөрәк канын
Алтын итеп сыккан этләрне,
Өзгәләде алар зур йөрәген аның
Һәм кабергә илтеп этәрде...

Кулы богауланган ана кебек,
Халкы гына калды тилмереп,
Халкы гына җырын алып чыкты,
Дөнья читлекләрен җимереп.

Ләкин белми шагыйрь: кем соң аның
Чәчкәләргә бизи каберен.
Әй, кешеләр, үзе исән чакта
Белсәгезче шагыйрь кадерен!...

1954 ел

1 укучы. Р.Гарипов Башкортстанның киләчәген дә ирекле, көчле итеп күргән. Бу бигрәк тә “Дан сиңа, дан Башкортстан” шигырендә күреп була. Р.Сәлмәнов бу шигырьгә көй дә язган.

“Туфрагы да алтын туган җирнең
Кулларында булса останың.
Кысыйм мин оста кулларыңны:
Батыр түгел батыр ялгыз чакта,
Зур дуслыкта аның көч-даны.
Данлыйсың мин тугры дусларыңны.

2 укучы. Р.Гариповның “Курай”, “Ага сулар”, “Тормыш”, “Кеше” исемле шигырьләрен дә тирән эчтәлекле, фәлсәфи фикердә язылган.

Кеше көлсен, җырласын, сыкранмасын, янсын, канатлансын, шундай бай, бәхетле итеп күрәм киләчәкнең матур кешесен!”